# ТАТАРЛАРДА МАЛ ТОТУ ТРАДИЦИЯСЕНӘ БӘЙЛЕ МИФОЛОГИК КҮЗАЛЛАУЛАР[1]

*Ф.Х. Җәүһәрова*

Без татарлар үзебезнең күчмә тормышлы токымнан булуыбызны китаплардан укып кына түгел, каныбыз белән дә тоеп яшибез. Көндәлек яшәешебездә шул заманнардан бирле яратып әзерләнүче ризыкларыбыз: күзикмәк, бавырсак, чәк-чәк, каклаган каз, ат ите, баллы май, кызартып киптерелгән эремчек-кортларны рәхәтләнеп әзерлибез, кунак сые буларак еш кына табын түренә куябыз. Безнең күчмә тормыш рәтен белүебез татар яшәешенең тагын бер күренешендә – мал тоту һәм аңа булган мөнәсәбәтләр һәм ышану системаларында сакланып калган. Безнең өчен ат, сыер, сарык тоту бәрәкәтле, хуҗалыкка иркен яшәргә мөмкинлек бирүче гамәл. Тиккә генә халкыбыз "малы барның көе бар" дигән мәкальне еш кулланылышта йөртми. Абзар-курасында аты кешнәп, сыеры мөгрәп торган хуҗалык кына татар акылында киләчәкле буларак кабул ителә. Шуңа күрә татар кешесе өчен "Ишегалдыңны чирәм бассын" дип әйтү гаиләнең бәрәкәтен бетерүгә юнәлтелгән иң куркыныч каргыш буларак билгеләнә.

Мал-туар тотуны гаилә иминлеген, бәрәкәтен тәэмин итү чарасы буларак таныган татар кешесе өчен бик борынгыдан килгән малны явыз күзләрдән, көнчеләрдән саклау, үрчемлеген киметмәү гамәлләре системасы яшәп килә. Әлбәттә, моның нигезендә мифологик ышанулар ята. Бүгенге мәкалебездә без аларның берничәсенә тукталып, магик эчтәлекнең асылында борынгы төрки бабаларыбыздан килгән мифологик күзаллаулар ятуын күрербез.

Татарлар яшәгән төрки төбәкләргә оештырылган экспедицияләр барышында без бервакытта да көтү китүен, кайтуын каршылау, малларны абзарга ябу, сөт саву, күрше-күләнгә сөт бирү гадәтләренә игътибар бирми калмыйбыз. Хуҗабикә белән авыл тормышы, яшәеш турында гәпләшкән арада сүз ара сүз чыгып, сыер абзарында эленгән тишекле агач йомычкаларына, кайбер якларда тишекле зур ташларга күз салып, әлеге предметларның ни максаттан монда шулай эленеп торуларын сораштырабыз. Хуҗабикәләр гадәттә безгә төрле төбәкләрнең бар авылларында да әйтелүче "Мин кияүгә килгәндә шунда эленеп тора инде, гел шунда тора иде. Әби-бабадан калган таш (агач)," – диләр. "Сез ул ташны берәр нәрсә өчен кулланасызмы?" – дигән сорауга да кызыклы гына "Сыер кысыр калса сөт савытында уганда әлеге агач (таш) тишеге аркылы

---

[1] Статья выполнена в рамках проекта РГНФ № 11-14-16002а/ В / 2012 (РГНФ) «Мифологические персонажи в культурной традиции татар Заказанья».

савып карыйбыз, булышкан кебек була. Гомән тишекле агач, ташларны үрчем билгесе диләрбит. Әби-баба гадәте инде. Алар өйрәткәнне эшлибез. Мал кысыр калу яман бит," – кебек җаваплар алырга туры килгәли [Иск. 1]. Мондый саклау магиясенә корылган тишекле ташларны (агачларны) безгә Саба, Теләче, Биектау районнары татар авылларында шактый күп күрергә туры килде. Биредә шуны да анықларга кирәк, бу очракта теләсә кайсы таш яки агач кулланылмый. Бары тик тишеге табигый рәвештә, ягъни тишеге ботак тишеге булган агач яки үзе тишекле булган ташлар гына яраклы дип табыла. Теләче районы авылларында абзар-кураларда тишекле зур чуерташларга юлыккан булсак, Биектау районы авылларында тишекле известьняклар кулланылышта йөри. Шунысы кызыклы, тишекле ташлар белән беррәттән Биектау районы авылларында Корбан Гаете бәйрәмендә атап чалынган корбанның тишекле умыртка сөякләре дә абзарда тотылучы малның үрчемлеген киметмәүне тәмин итү чарасы буларак эленеп тора.

Дөнья халыкларының бик күбесендә тишекле таш, агач, сөяк үрчем символы буларак аңлатыла. Тишекле таш, шул исәптән тау куышлары да хатын-кыз җенесе белән тиңләштерелеп аңлатыла [2, б. 132]. Борынгы төркиләрнең археологиясен, тарихын, генезисын өйрәнүче күренекле галим Л. Кызласов Алтай таулары куышларында күпләп табылучы сызгыра торган тишекле укларның күп булуын да нәкъ менә тау куышының хатын-кыз җенесле булуына ышануга нигезләп аңлатуны кулай күрә һәм ир-атлар тарафыннан уклар атылып, тауны аталандыру, шуның бәрабәренә тау итәкләрендә, битләрендә утлап йөрүче малларның үрчемле булуын, үлән-агачларның күп булып үсүләрне тәэмин итүгә китерүче гамәл буларак башкарылуына бәйләп аңлата.[1, б. 72-79.] Шушындый фикерләрне Россия һәм Европа халыкларының традицион мәдәниятен өйрәнүче галимә Т.Б. Щепанская да тишекле таш, агач, сөякләрнең үрчемне тәэмин итү белән бәйле мифологик ышануларга нигезләнгән предметлар булуын дәлилли [2, б. 125.]

Әстерхан өлкәсенең кайбер татар авылларында экспедициядә йөргәндә мал-туар күп тотучы гаиләләр ишегалдында кызыл тукыма кисәгенең эленгән булуы да безнең игътибарыбызны җәлеп итмичә калмады. Безнең әлеге тукыма кисәгенең нәрсә өчен кулланылуына бәйле соравыбызга "күз тимәсен, малларыбыз исән-сау булсыннар өчен," – дигән җавапларны ишетергә туры килде [Иск. 2.]. Үзебезнең Татарстан авылларында гына да кичен көтү кайтканын күзәткән кеше күп кенә сыерларның маңгайларына бәйләнгән кызыл чүпрәк кисәкләрен, тасмаларны, чукларны хәзер дә күрә ала. Башлыча, мондый тасмаларны сөтле сыерларга, беренче тапкыр көтүгә куылган яшь

таналарга, үгез, бозауларга тагып, бәйләп чыгаралар. “Ни өчен кызыл төс кулланалар соң?” – дигән сорау биредә урынлы. Кызыл төснең төрле халыклар традицияләрендә төрлечә кабул ителү системалары бар. Беренче чиратта, безнең борынгы бабаларыбыз төркиләр акылында кызыл төс – кояш баешы, ягъни көнбатыш төсе буларак кабул ителүен билгеләргә кирәк. Шул ук вакытта алтай төркиләрендә, кытайларда кызыл төс магик көчкә, сихәт кертүче иң көчле төсләр буларак кабул ителүен дә ассызыклый. Кызыл төс көч, дәрт, куәт кертүче төс буларак та билгеле. Безнең сөннәтче бабайлар да сөннәт йоласын үтәү вакытында тиккә генә сөннәткә утыртылучы ир баланың сөннәт алдыннан гаурәтенә кызыл чүпрәк капламаган яисә кызыл итәк, төпсез ыштан киертмәгән. Бу очракта, бер яктан, кызыл төс сихәтләндерүче төс буларак кулланса, икенче яктан, киләчәктә ир-егет булып җитешүгә тиешле баланың ирлек көчен саклау, ныгыту мәгънәсе дә күзалламый калмагандыр.

Инде сыер малына кызыл чүпрәк, тасма, бау кисәкләре бәйләүнең эчтәлек катламнарына да тукталып үтик. Тизрәк карлар эреп, көтүлекләр ачылуга болыннарны тутырып сыер, сарык маллары йөри башлар. Авыл кешесе беренче көтү чыгар алдыннан сыер маңгаена кызыл тасмасын, бавын яңарту, миләш ботаклары бәйләү мәшәкатьләре күрә. Бу мәшәкатьләр асылында да гаилә бәрәкәте, ныклыгын тәэмин итүче олы малны кадерләп асраган һәр хуҗаның малының күзләр тимичә көтүнең һәр көнендә исән-имин туры өйгә кайтып керүенә өмете салынган. Шушы ышанулары системасын кулланып, бисмилласын әйтеп капкасын олы малларына халкыбызның чиксез күп гаиләләре һаман да ача бирә.

## Әдәбият исемлеге

1. Кызласов И.Л. Материалы к ранней истории тюрков. I. Древнейшие свидетельства об армии / И.Л. Кызласов // Российская археология № 3. С. 72-79.

2. Щепанская Т.Б. Пронимальная символика / Т.Б. Щепанская // Женщина и вещественный мир культуры у народов России и Европы / под ред. Т.А. Бернштам. – Спб.,1999. – 249 с.

## Искәрмәләр

1. Халиуллина Нәзирә Галиәхмәт кызы, Саба районы кече Шыңар авылында 1937 елда туган (автор тарафыннан 2004 елда 27 майда язып алынды).

2. Сиражитдинов Шамил 1949 елда Әстерхан өлкәсе Яңа Болгар авылынды туган (автор тарафыннан 2011 елда язып алынды).